ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

**2026 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, чит дәүләтләр, чит федератив дәүләтләр субъектлары, чит дәүләтләрнең административ-территориаль берәмлекләре парламентлары белән хезмәттәшлегенең якынча планы турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, чит дәүләтләр, чит федератив дәүләтләр субъектлары, чит дәүләтләрнең административ-территориаль берәмлекләре парламентлары белән хезмәттәшлегенең якынча планын (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. 2026 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, чит дәүләтләр, чит федератив дәүләтләр субъектлары, чит дәүләтләрнең административ-территориаль берәмлекләре парламентлары белән хезмәттәшлегенең якынча планы үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 24 декабре
№ 524-VII ДС

2025 елның 24 декабрендәге
524-VII ДС номерлы
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы карары белән
РАСЛАНДЫ

**2026 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, чит дәүләтләр, чит федератив дәүләтләр субъектлары, чит дәүләтләрнең административ-территориаль берәмлекләре парламентлары белән хезмәттәшлегенең якынча планы**

| № т/б | Чара исеме | Үткәрү вакытлары | Җаваплылар |
|---|---|---|---|

**1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының икеяклы парламентара хезмәттәшлеге**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.1. | Россия Федерациясе субъектлары парламентлары белән хезмәттәшлек турында шартнамәләр, килешүләр әзерләү һәм аларны имзалау (аерым исемлек буенча) | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Секретариаты |
| 1.2. | Хезмәттәшлек турында килешүләрне һәм беркетмәләрне гамәлгә ашыру буенча уртак эшче комиссияләр төзү | | |
| 1.3. | Татарстан Республикасы парламент делегацияләренең Россия Федерациясе субъектларына һәм чит илләргә визитларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру (рәсми чакырулар буенча) | | |
| 1.4. | Россия Федерациясе субъектлары дәүләт | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | хакимиятенең закон чыгару органнары белән закон чыгару эшчәнлеге мәсьәләләре буенча парламент эшчәнлеге тәҗрибәсен алмашу, уртак конференцияләр, семинарлар, түгәрәк өстәлләр үткәрү | | |
| 1.5. | Закон актларын һәм эчке куллану документларын (парламентлар регламентларын, комитетлар һәм комиссияләр турында, аппаратлар хакында нигезләмәләрне һ.б.), парламент эшчәнлеге турында мәгълүмати-аналитик материалларны, шулай ук Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кергән закон чыгару инициативалары проектларын алмашу | | |
| 1.6. | Мәгълүмат һәм башка элемтәләрне киңәйтү, Россия Федерациясе субъектлары парламентлары, чит дәүләтләр һәм чит дәүләтләрнең административ-территориаль берәмлекләре парламентлары (Беларусь Республикасы, Үзбәкстан Республикасы, Төрекмәнстан) белән | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | хезмәттәшлекне үстерү | | |
| 1.7. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында чит дәүләтләр делегацияләрен кабул итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Секретариаты |
| 1.8. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары линиясе буенча оештырылган рәсми делегацияләр визитларында катнашуы | ел дәвамында (аерым график буенча) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |
| 1.9. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының Татарстан Республикасында уздырыла торган халыкара форумнарда һәм конференцияләрдә катнашуы. Килә торган делегацияләр белән эшләү, чит ил парламент делегацияләренең һәм Россия Федерациясе субъектлары | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | делегацияләренең Татарстан Республикасына визитлары кысаларында депутат коллегалар белән очрашулары һәм консультацияләр | | |
| 1.10. | Россия Федерациясенең яңа субъектлары парламентлары белән парламентара хезмәттәшлекне киңәйтү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |
| 1.11. | Беларусь һәм Россия регионнарының XIII Форумы чараларында катнашу (Минск өлкәсе) | июнь – июль | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретариаты |
| 1.12. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Каракалпакстан Республикасы Жокаргы Кенес (Үзбәкстан Республикасы) белән парламентара хезмәттәшлеген үстерү буенча эшче төркем эшчәнлеген тәэмин итү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары М.Г. Әхмәтов |

## 2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының күпьяклы парламентара хезмәттәшлеге

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2.1. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Россия Федерациясе | Закон чыгаручылар советы эше | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Федераль Собраниесе каршындагы Россия Федерациясе Закон чыгаручылар советы эшендә катнашуы. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнары җитәкчеләре белән очрашулар. Россия Федерациясе Закон чыгаручылар советының Халыкара хезмәттәшлек проблемалары комиссиясе эшен оештыру | планы нигезендә ел дәвамында | Рәисе (Халыкара хезмәттәшлек проблемалары комиссиясе рәисе һәм Закон чыгаручылар советы Президиумы әгъзасы буларак), Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Секретариаты |
| 2.2. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Идел буе федераль округының Закон чыгаручылар советы эшендә катнашуы. Идел буе федераль округының Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнары җитәкчеләре белән очрашулар | Идел буе федераль округының Закон чыгаручылар советы эше планы нигезендә ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Секретариатының аналитика бүлеге |

## 3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларының һәм комиссияләренең парламентара хезмәттәшлеге

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3.1. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларының Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советының һәм Дәүләт Думасының профильле комитетлары белән хезмәттәшлеге. Парламент тыңлауларында, түгәрәк өстәлләрдә, | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | конференцияләрдә һәм башка чараларда катнашу | | |
| 3.2. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларының Россия Федерациясе субъектлары, шул исәптән Идел буе федераль округы составына керүче, парламентларының профильле комитетлары (комиссияләре) белән хезмәттәшлеге | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |
| 3.3. | Түбәндәге мәсьәләләр буенча Россия Федерациясе субъектлары тәҗрибәсен өйрәнү: | | |
| | җирле үзидарә турындагы законнарны гамәлгә ашыру | ел дәвамында | Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты |
| | Россия Федерациясе республикаларын конституциячел-хокукый үстерү, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнары тарафыннан хокукый мониторинглауны гамәлгә ашыру тәҗрибәсен өйрәнү | | Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты |

**4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат берләшмәләренең парламентара хезмәттәшлеге**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4.1. | Россия Федерациясе субъектларында «ЕДИНАЯ РОССИЯ» Бөтенроссия сәяси партиясе депутат | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «ЕДИНАЯ РОССИЯ» |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | берләшмәләренең региональ координация советлары линиясе буенча үзара хезмәттәшлеге | | фракциясе җитәкчесе |
| 4.2. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «Мәрхәмәт – Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе һәм Идел буе федераль округының Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте закон чыгару органнарының хатын-кыз депутатлары катнашында дискуссия мәйданчыклары утырышлары | квартал саен | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Мәрхәмәт – Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе җитәкчесе |
| 4.3. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «Мәрхәмәт – Милосердие» хатын-кыз депутатлары берләшмәсенең Халыкара хатын-кызлар клубы катнашучылары белән хезмәттәшлеге | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «Мәрхәмәт – Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе җитәкчесе |
| 4.4. | Идел буе федераль округының Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнарында КПРФ фракцияләре депутатлары белән торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында КПРФ фракциясе җитәкчесе |

## 5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының парламентара хезмәттәшлеге

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5.1. | Идел буе федераль | ел дәвамында | Аппаратның |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | округының Закон чыгаручылар советы эшчәнлеге кысаларында Идел буе федераль округының Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнары тәҗрибәсен өйрәнү | | структур бүлекчәләре |
| 5.2. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты структур бүлекчәләре хезмәткәрләренең Идел буе федераль округының Закон чыгаручылар советы эшчәнлеге кысаларында уздырыла торган семинар-киңәшмәләрдә катнашуы | ел дәвамында | Аппаратның структур бүлекчәләре |
| 5.3. | Идел буе федераль округының Закон чыгаручылар советы каршындагы Сакчыл идарә системасы нәтиҗәләрен гамәлгә кертү комиссиясе эшендә катнашу | ел дәвамында | Аппаратның структур бүлекчәләре |
| 5.4. | Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнары аппаратларының оештыру эшчәнлеген планлаштыру тәҗрибәсен өйрәнү | ел дәвамында | Оештыру идарәсе |
| 5.5. | Россия Федерациясе субъектлары законнарын мониторинглау | ел дәвамында | Хокук идарәсе |
| 5.6. | Үз эшчәнлекләрен цифрлаштыру мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Федераль | ел дәвамында | Эшләр идарәсе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Собраниесенең, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнарының, чит дәүләтләрнең эш тәҗрибәсен өйрәнү | | |
| 5.7. | Электрон документ әйләнеше системасында эшләү, документлар үтәлешен тикшереп тору, эш номенклатурасын төзү, закон проектларына лингвистик экспертиза уздыру, утырышларның стенографик хисапларын әзерләү өлешендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнары аппаратларының эш тәҗрибәсен өйрәнү | ел дәвамында | Документлар белән тәэмин итү идарәсе |
| 5.8. | Идел буе федераль округының Закон чыгаручылар Советы утырышларында катнашу кысаларында массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү өлкәсендә Идел буе федераль округының Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнары матбугат хезмәтләре тәҗрибәсен өйрәнү | ел дәвамында | Матбугат хезмәте |